ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтү турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры А.Р. Хәйруллинның дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтү турында мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры А.Р. Хәйруллин мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына тәкъдим итәргә:

2.1. Системалы эшне түбәндәгеләр буенча дәвам итүне:

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматка күчерү;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларын кыскарту, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар арасында мәгълүмати хезмәттәшлек процессларын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталын үстерү.

2.2. Халыкка дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтүнең сыйфатын арттыруны, шул исәптән күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә һәм муниципаль хезмәтләргә карата тикшеренүләр үткәрү һәм алардан файдаланучылар арасында тестлар уздыру юлы белән, тәэмин итүне.

2.3. Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге эшен камилләштерүдә булышуны.

2.4. Республика башкарма хакимияте органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтү

мәсьәләләре буенча кирәкле методик ярдәм күрсәтүне һәм консультация бирүне.

3. Республика башкарма хакимият органнарына һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

3.1. Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтү буенча уртак эшне дәвам итүне.

3.2. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларын кыскартуда, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә мәгълүмати хезмәттәшлек процессларын оптимальләштерүдә (реинжиниринг) булышуны.

3.3. Татарстан Республикасында халык һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында цифрлы сервисларны, шул исәптән «Локоло» сервисын, популярлаштыру буенча комплекслы чаралар күрүне.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкка дәүләт хезмәтләре (федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелә торган) һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларының үтәлешенә контрольне көчәйтүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы халкына дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмаларга, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматка күчерүдә республика башкарма хакимият органнарына һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына үз компетенцияләре кысаларында ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә (килешү буенча).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2215-VI ДС